СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 г. Агрыз № 5-3

«Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына конкурс игълан итү турында»гы 15.12.2025 ел № 4-2 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын раслау хакында" 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» 15.12.2025 ел, № 4-2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс түбәндәге шартларда уздырыла:

1) Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына кандидатның булуы:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы;

б) югары белем;

в) кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

г) милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешманың, дәүләт органының, җирле үзидарә органының җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында кимендә ике ел идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе;

д) Башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле күләмдә эшлекле сыйфатлар һәм күнекмәләр:

- белемне дә кертеп, һөнәри белемнәр булу,

Россия Федерациясе Конституциясе,

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»федераль законнар,

Татарстан Республикасы Конституциясе,

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законын, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексын, муниципаль берәмлек Уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны җайга сала торган, шул исәптән Башкарма комитет җитәкчесе компетенциясенә һәм Башкарма комитет эшчәнлеген алып баруга караган мәсьәләләрне дә кертеп,

-муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен һәм аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитет эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләү, әлеге эшчәнлекнең яңа формаларын һәм ысулларын эзләү, аларны гамәлдә гамәлгә ашыру механизмнарын эшләү сәләте;

- үз эшчәнлегеңне, Башкарма комитетның, аның органнарының һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә буйсынучы хезмәткәрләрнең эшчәнлеген планлаштыру, оештыру һәм анализлау сәләте;

- этик нормаларны белү һәм аларны хезмәт аралашуында куллану сәләте;

2) кандидатның муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләр булмавы.»

2.Бу карарны Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 15 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов